СОВЕТ
НАЛАСИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Вахитова, д. 64, с.Наласа,
Арский муниципальный район, 422018

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
НАЛАСА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
М.Вахитов урамы, 64 йорт, Наласа авылы,
Арча муниципаль районы, 422018

Тел. (84366)50-2-25, факс (84366)50-2-25. E-mail: Nalas.Ars@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы**

**КАРАРЫ**

**19 октябрь 2020 ел** **№ 2**

**Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге Урта Бирәзә авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль Наласа авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы Карар бирде:

1. Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге Урта Бирәзә авылында Урта Бирәзә авылы, Татарстан урамы, 90 йорт адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2020 елның 08 ноябренә 13 сәгать 00 минутта халык җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге Урта Бирәзә авылында Урта Бирәзә авылы, Татарстан урамы, 90 йорт адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2020 елның 08 ноябренә 15 сәгать 00 минутта халык җыенының икенче этабын билгеләргә.

3. Торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлүне территория буенча башкарырга.

1нче этап: Татарстан, М.Вахитов урамында яшәүчеләр

2нче этап: Фәйзрахмановлар, Х.Такташ урамында яшәүчеләр

4. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез 2021 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 175сум тәшкил иткән балачактан инвалидлардан тыш, 350 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

Җирлек территориясен төзекләндерү:

«Ак яр» һәм «Фазыл чишмәсе» территорияләрен төзекләндерү, «Фазыл чишмәсе»ннән Урта Бирәзә авылына сууткәргеч торбалар салу.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

| “ӘЙЕ” | “КАРШЫ” |
|---|---|
| | |

5. Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге Урта Бирәзә авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы итеп Наласа авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Наласа авылы, М.Вахитов урамы, 64 йорт; ТР, Арча районы, Урта Бирәзә авылы, Татарстан урамы, 90 йорт адреслары буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

«Наласа авыл җирлеге» муниципаль
берәмлеге башлыгы урынбасары: И.Р. Төхфәтуллин